КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 19 ноябрь г.Казань № 1006

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 7 февраль, 73 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 7 февраль, 73 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 9 апрель, 228 нче; 2014 ел, 1 ноябрь, 831 нче; 2015 ел, 17 апрель, 263 нче; 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы; 2015 ел, 30 октябрь, 825 нче; 2016 ел, 31 март, 184 нче; 2016 ел, 22 сентябрь, 675 нче; 2016 ел, 1 ноябрь, 804 нче; 2016 ел, 31 декабрь, 1085 нче; 2017 ел, 20 февраль, 103 нче; 2017 ел, 24 июнь, 424 нче; 2017 ел, 26 июнь, 432 нче; 2017 ел, 4 октябрь, 759 нчы, 2017 ел, 27 ноябрь, 916 нчы; 2018 ел, 26 февраль, 113 нче; 2018 ел, 27 апрель, 305 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә һәм 1 нче пунктта «2014 – 2020» саннарын «2014 – 2021» саннарына алыштырырга;

2 нче һәм 6 нчы пунктларда тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасын (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин